Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районының
Арча шәһәр муниципаль берәмлеге
Арча шәһәр
башкарма комитеты
422000, Арча ш., Совет мәйданы, 27
тел. 3-15-25, 3-12-35

Муниципальное образование
город Арск
Арского муниципального района
Республики Татарстан
исполнительный комитет
города Арск
422000, г. Арск, площадь Советская , 27
тел. 3-15-25, 3-12-35

# КАРАР

« 09 » октябрь 2015 ел № 166

**Сатып алу юлы белән милекчедән җир кишәрлегенә һәм торакка хокукның өлешен муниципаль милеккә тартып алу**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль закон, Россия Федерациясе Граждан кодексының 279 статьясы, Россия Федерациясе Торак кодексының 32 статьясындагы 1-3, 10, 11 пунктлары, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 7 апрелендәге 329 номерлы карары белән расланган 2013-2015 елларга Арча муниципаль районының авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча муниципаль адреслы программасы нигезендә Арча муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. Билгеләнгән тәртиптә авария хәлендә дип танылган 161/1000 16:09:010104:62 кадастр номерлы Татарстан Республикасы, Арча муниципаль районы, Арча шәһәре, Комаров урамы, 29 йорт 3 фатир адресы буенча 35,3 кв.м мәйданлы торакны (фатир) (010104:187 кадастр номерлы җир кишәрлегендә урнашкан ) хокукның өлешен милекчедән муниципаль милеккә алырга.

2. Милекчегә муниципаль ихтыяҗлар өчен җир кишәрлегенә һәм торакка хокукта күрсәтелгән өлешне алу турында хәбәр итәргә.

3. Милекчегә Россия Федерациясе Торак кодексының 32 статьясындагы 7 өлешендә каралган җир кишәрлегенә һәм торак бинага хокуктагы өлеш өчен, шулай ук барлык зыянны түләүне 389 076 (өч йөз сиксән тугыз мең җитмеш алты) сум 60 тиен тәкъдим итәргә.

4.Әлеге карарны кабул ителгәннән соң ун көн эчендә:

1) әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru).

2) әлеге карарның күчермәсен күчемсез милек хокукы иясенә җибәрергә;

3) әлеге карарның күчермәсен күчемсез милеккә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашыручы органга җибәрергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп тору Арча шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары К. В.Гомәровка йөкләргә.

Арча шәһәре башкарма
комитет җитәкчесе Р. Ф. Касыймов